**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**ЖУКОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЖУКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 53-2-22, факс 53-2-22

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30 .11. 2023** **№ 3**

**2024 елда гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Жуково авыл җирлегенең Берлек торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Жуково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына ярашлы рәвештә:
1. 2023 елның 14 декабрендә Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Берлек авылы, Вахитов урамы, 17 нче йорт адресы буенча 10 сәгать 30 минутка гражданнарның 2024 елда Тәтеш муниципаль районы Жуково авыл җирлегенең Берлек торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләнсен.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Жуково авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, I төркем инвалидлардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә:
- Берлек бистәсендәге авыл эчендәге юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу?».

» КАРШЫ «РИЗА”

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Жуково авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм үткәрергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Жуково авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында " (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**Җитәкче** **Н.А.Борисова**